# Бәзәкә мәчетендә “Балаларны укыту, рухи яктан сәламәтләндерү үзәге” эшен тәмамлады

11 июльдән 23 июльгә кадәр Бәзәкә мәчетендә “Балаларны укыту, рухи яктан сәламәтләндерү үзәге” эшләде. Балалар арасында Коръән уку, Коръәннән сүрәләр ятлау буенча дәресләр, шулай ук “Сорау-җавап” викторинасы, төрле спорт уеннары да узды.

Шушы изге эштә катнашкан барлык якташларыбызга Аллаһыбызның рәхмәтләре булсын! Болар Илгиз кызы Тәнзилә, Минәхмәт кызы Фәимә, Гайнельгыйлем кызы Гөлфирә, мөгәллимә Зөфәр кызы Айгөл, Зиннур абый кызлары Розалия һәм Гүзәлия, Камалетдинова Тәнзилә, шулай ук оештыруда булышкан иганәчеләребез. Барыгыз да исән-сау, бәхетле булыгыз! Изге гамәлләрегез үзегезгә һәм балаларыгызга йөз булып кайтсын!

*Имам Мехаматнур хәзрәт, 2022 ел, 23 июль*






ТӘХӘРӘТ ХАНӘ







